# КАРАЧТАУ АВЫЛЫ КӨЕ

*Татар халык җыры*

Агыйделнең парахуты
Җиталмый кызыл ярга шул;
Җиталмый, дуслар, җиталмый
Яратып сөйгән ярга.

Агыйделнең парахуты —
Бездән еракта уты шул;
Сине уйламый үтә микән
Сәгатьнең бер минуты?!

Агыйдел сулары булсам,
Уралып агар идем шул;
Яңгыр тамчылары булсам,
Алдына тамар идем.